**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

# ПРИКАЗ

# БОЕРЫК

07.12.2021 № 624-осн

г.Казань

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 6 июлендәге 513-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республиасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге карары белән расланган Татарстан Республиасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында бертөр нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 8 ноябрендәге 1058 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 6 июлендәге 513-осн номерлы боерыгы (2018 елның 4 апрелендәге 186-осн номерлы, 2019 елның 3 июнендәге 543-осн номерлы боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 7 декабрь 624 -осн номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) 2017 елның 6 июлендәге 513-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«башкарма орган эшчәнлегенә иҗтимагый контрольлекне гамәлгә ашыру»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Иҗтимагый советның бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы территориясендә урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүдә катнашу;

Министрлык тарафыннан карарлар кабул ителгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлыкның төп эшчәнлек юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең хәбәрдарлык дәрәҗәсен үстерү;

җәмгыятьтә коррупциягә юл куймаучанлык формалаштыру.»;

2 нче бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.4 пунктын өстәргә:

«2.4. Әлеге максатларга ирешү һәм куелган бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет:

Татарстан Республикасы территориясендә урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүдә буенча тәкъдимнәр әзерли;

коррупциягә каршы көрәш буенча эшчәнлектә катнаша;

«Россия Федерациясендә иҗтимагый контрольлек нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Министрлык тарафыннан эшләнә торган, Иҗтимагый совет утырышында алдан фикер алышмыйча кабул ителә алмый торган, Татарстан Республикасы территориясендә урман мөнәсәбәтләре мәсьәләләренә кагылышлы норматив хокукый актларның проектларына иҗтимагый экспертиза уздыруны оештыра;

Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатына мониторингта катнаша;

Татарстан Республикасы территориясендә урман мөнәсәбәтләре мәсьәләләренә кагылышлы, Министрлык тарафыннан дәүләт сатып алуларының нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша;

дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс комиссияләре һәм дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләренә аттестация үткәрү өчен аттестация комиссияләре эшендә катнаша.»;

3 бүлектә:

3.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Нигезләмәнең 6.6 пунктында каралган нигезләр булуы.»;

3.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килгәндә.»;

3.8 пунктта:

беренче абзацта "яки рәис урынбасарының" сүзләрен алырга;

икенче абзацта "яисә рәис урынбасарына" сүзләрен алырга.

түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Иҗтимагый советта мәнфәгатьләр каршылыгы

6.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы – Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынучанлыгы үзенең бурычларын тиешенчә, объектив һәм риясыз үтәүгә (вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга) йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган һәм бу вакытта Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынучанлыгы һәм Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары арасында каршылык килеп чыга яки килеп чыга ала торган хәл.

6.2. Иҗтимагый совет әгъзасының үзенең вәкаләтләрен объектив һәм риясыз гамәлгә ашыруга йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынучанлыгы Иҗтимагый совет әгъзасы тарафыннан акча, кыйммәтләр, башка төрле мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар алу яисә үзе яки өченче затлар өчен хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге дигәнне аңлата.

6.3. Иҗтимагый совет әгъзасы барлыкка килгән мәнфәгатьләр каршылыгы турында яки аның барлыкка килү ихтималлыгы турында бу хакта мәгълүм булуга Иҗтимагый совет рәисенә һәм министрга язмача формада хәбәр итәргә, ә Иҗтимагый совет рәисе бу хакта Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язмача формада җиткерергә тиеш.

Иҗтимагый совет рәисе барлыкка килгән мәнфәгатьләр каршылыгы турында яки аның барлыкка килү ихтималлыгы турында бу хакта мәгълүм булуга язмача формада министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына хәбәр итәргә тиеш.

5.4. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яки җайга салу буенча, шул исәптән мәнфәгатьләр каршылыгының бер ягы булып торган Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктатып тору яки туктату турында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы билгеләгән тәртиптә Министрлык министрына тәкъдим кертү юлы белән, чаралар күрергә бурычлы.

Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Иҗтимагый совет эшчәнлегендә коррупция хәтәрлекләренә бәя уздыра һәм Иҗтимагый совет әгъзаларының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашуын булдырмау максатларында аларны минимальләштерү чараларын күрә.

6.5. Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет рәисе өч эш көне эчендә бу хакта язмача формада Министрлык министрына һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына хәбәр итә.

Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет әгъзалары өч эш көне эчендә бу хакта

язмача формада министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына хәбәр итә.

6.6. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүмат алынган очракларда, Иҗтимагый совет әгъзасының Иҗтимагый совет эшендә катнашуын туктатып тору турында министрга тәкъдим кертә.

Министрның Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктатып тору турындагы карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.

6.7. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә торган шартлар бетерелмәсә яки Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты расланса, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы министрга Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында тәкъдим кертә.

Министрның Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен бетерү турындагы карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.

6.8. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә торган шартлар бетерелмәсә (расланмаса) һәм (яки) Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты расланмаса, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Министрлык министрына Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен яңартып җибәрү турында тәкъдим кертә.

Министрның Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен яңадан торгызу турындагы карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.».